РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.01.2024 Олы Кайбыч ав. № 4

Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген һәм муниципаль вазыйфалар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Президентының «Гражданнарны билгеләгәндә һәм биләгән очракта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле муниципаль вазыйфалар исемлеген расларга (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2023 елның 10 февралендәге 9 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар эше һәм коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы

оештыру бүлеге баш белгеченә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру хокукый бүлеге баш белгеченә Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән муниципаль вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләргә һәм затларга үзләре алган керемнәр, чыгымнар, милек хокукында аларныкы булган мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милек хокукындагы мөлкәтләре турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен имза куйдырып җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләнә.

А. И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 2024 е. «18» 01
4 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1. Кайбыч муниципаль районы Советы Аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары** | | | |
| 1 | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Совет Аппараты җитәкчесе | 1 вазыйфа |
| 2 | Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары | Оештыру эше бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| 3. | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Муниципаль район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | 1 вазыйфа |
| | | Кайбыч муниципаль районы Советы Аппаратының оештыру бүлеге баш белгече | 1 вазыйфа |
| | | Бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенең баш белгече | 1 вазыйфа |
| | Барлыгы: | | 6 вазыйфа |
| **2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары** | | | |
| 1. | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Башкарма комитет Җитәкчесе | 1 вазыйфа |
| | | Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисадый мәсьәләләр) | 1 вазыйфа |
| | | Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | 1 вазыйфа |
| | | Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары | 1 вазыйфа |
| | | Эшләр идарәчесе | 1 вазыйфа |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары | Оештыру-хокук бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Гомуми бүлек башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Мәгариф бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Мәдәният бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | ЗАГС бүлеге җитәкчесе | 1 вазыйфа |
| | | Территориаль үсеш бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| | | Опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| 3. | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Мәгариф бүлеге башлыгы урынбасары | 1 вазыйфа |
| | | Муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе | 1 вазыйфа |
| | | Яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторы мөдире | 1 вазыйфа |
| | | Архив секторы мөдире | 1 вазыйфа |
| | | Оештыру-хокук бүлегенең баш белгече | 1 вазыйфа |
| | | Баш белгеч -архитектор | 1 вазыйфа |
| | | Опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече | 1 вазыйфа |
| | | Территориаль үсеш бүлегенең баш белгече | 2 вазыйфа |
| | | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре-баш белгеч | 1 вазыйфа |
| | | инфраструктура үсеше бүлегенең ТКХ буенча баш белгече | 1 вазыйфа |
| | | Балигъ булмаганнар арасында гаиләжитешсезлекләрен һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор -баш белгеч | 1 вазыйфа |
| | | Административ комиссия баш белгече | 1 вазыйфа |
| | Барлыгы: | | 26 вазыйфа |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **3. Җирле үзидарәнең башка органында, башка җирле үзидарә органы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары** | | | |
| 1. | Югары вазыйфалар муниципаль хезмәт | Финанс-бюджет палатасы рәисе | 1 вазыйфа |
| | | Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе | 1 вазыйфа |
| | | Рәис урынбасары - финанс-бюджет палатасының бюджет бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| 2. | Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары | Финанс-бюджет палатасының исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы | 1 вазыйфа |
| 3. | Муниципаль хезмәтнең башка вазыйфалары | Финанс-бюджет палатасы баш белгече | 3 вазыйфа |
| | | Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы баш белгече | 1 вазыйфа |
| | Барлыгы: | | 8 вазыйфа |
| **4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләрендә муниципаль хезмәт вазыйфалары** | | | |
| 1. | Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | Башкарма комитет җитәкчесе (Олы Кайбыч авыл җирлеге) | 1 вазыйфа |
| 2. | | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары секретарьлары (Олы Кайбыч, Багай, Олы Подберезье, Олы Урсак, Борындык, Колаңгы, Кошман, Кече Мәми, Мәлки, Мөрәле, Надеждино, Иске Тәрбит, Ульянково, Федоровский, Хуҗа Хәсән, Чүти, Ябалак) | 17 вазыйфа |
| | Барысы: | | 18 вазыйфа |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 2024 е. «18» 01
4 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле муниципаль вазыйфалар исемлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советында муниципаль вазыйфалар:** | | | |
| 1 | Югары муниципаль вазыйфалар | Муниципаль район башлыгы (муниципаль район Советы рәисе), муниципаль район Советы депутаты | 1 вазыйфа |
| | | Муниципаль район башлыгы урынбасары (муниципаль район Советы рәисе урынбасары), муниципаль район Советы депутаты | 1 вазыйфа |
| | | Контроль-хисап палатасы рәисе | 1 вазыйфа |
| | | Авыл җирлеге башлыгы (авыл җирлеге Советы рәисе), муниципаль район Советы һәм авыл җирлеге Советы депутаты | 16 вазыйфа |
| | Барысы: | | 19 вазыйфа |
| 2. | Кайбыч муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатлары (муниципаль район Советы депутатларыннан һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче авыл җирлекләре Советларыннан башка) | | |
| 2 | Депутатлар | Муниципаль район Советы | 34 вазыйфа |
| | | Авыл җирлекләре Советы | 129 вазыйфа |
| | Барысы: | | 163 вазыйфа |